СОВЕТ ЧЕБОКСАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Чапаева , 3 б, с. Чув.Чебоксарка
Новошешминский район ,423192

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧАБАКСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Чапай урамы, 3 б ,
Чабаксар авылы , Яңа Чишмә районы, 423192

тел.: (8-84348) 37-5-84, факс: (8-84348) 37-5-84, Cheb.Nsm@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

“14”нче ноябрь, 2018 нче ел №52-90

**“Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге Советының“Физик затларның милкенә салым турында” 2014 нче елның 10 нче октябрендәге 40-76 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, 2014 нче елның 30 нчы октябрендәге “Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллануның бердәм датасын билгеләү турында” 82-ТРК нчы номерлы Татарстан Республикасы Кануны нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

I. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Чабаксар авыл җирлеге Советының 2014нче елның 10 нче октябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында” 40-76 нчы карарына (11.09.2015 № 43-109, 12.10.2015 № 2-8 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 2 нче пунктның 2, 3 нче пунктчаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

“ 2) фатир;
фатир өлешләре;
бүлмәләргә карата 0,2 процент;
3) торак йортлар;
торак йортларның өлешләре;
төзелеп бетмәгән объектлар,әгәр мондый объектларның билгеләнеше булып торак йорт проектлана икән;
составына бер торак йорт булса да кергән бердәм күчемсез комплексларга карата 0,3 процент”

2. Түбәндәге эчтәлекле 3 нче һәм 4 нче пункт өстәргә:

“3. Физик затлар милкенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:
3.1. 18 яшькә хәтле дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган гражданнар;
3.2. әлеге пунктның 3.1 нче пукнтчасында күрсәтелгән гражданнарның балалары.

4. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:
1) фатирлар, фатир өлешләре, бүлмәләр, торак йорт, торак йорт өлешләре.

Салым ташламасы салым түләүченең теләге буенча гаиләгә туры килә торган салым салуның бер объектына карата бирелә. Салым ташламасы Чабаксар авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләр тарафыннан салым түләүче милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым объектына карата түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра. Салым ташламасы бирелә торган объектлар турында хәбәрнамәне салым түләүче салым чоры булып торган елның 1 нче ноябренә кадәр салым органына тапшыра, аннан башлап күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла”.
3. 3 нче һәм 4 нче пунктларны шул рәвешле 5 нче һәм 6 нчы пунктлар дип санарга.

II. Әлеге карар 2019 нчы елның 1 нче гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин басылып чыкканнан соң бер айдан да иртә түгел.

III. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренд http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

IV. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Чабаксар авыл җирлеге башлыгы** **Моляков С.В.**